**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ВЯЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ " МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ IV ЧАКЫРЫЛЫШ**

**АЛТМЫШ ӨЧЕНЧЕ СЕССИЯ**

**2 нче Карар**

**Вязовка бистәсе,** **2025 елның 05 марты**

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Вязовка авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Советының 2024 елның 23 сентябрендәге LVII 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**
**«Җир салымы турында"**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешендәге 31 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының "Вязовка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «җир салымы турында»2024 елның 23 сентябрендәге LVII номерлы сессиясенең 1 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
2 өлешнең 1 абзацында «җир кишәрлекләренең кадастр хакыннан чыгып» сүзләрен төшереп калдырырга;
1.2 2 өлешнең 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
»- Татарстан Республикасы бюджетыннан, Бөгелмә муниципаль районы бюджетыннан финанслана торган бюджет, автоном, казна учреждениеләре файдалануындагы җир кишәрлекләренә карата 0,9 процент;";
1.3 3 өлешнең 12 абзацын төшереп калдырырга;
1.4 4 өлешкә түбәндәге эчтәлекле яңа пунктлар өстәргә:
«4.1. Календарь ел салым чоры дип танылa. Салым түләүче-оешмалар өчен хисап чоры итеп календарь елның беренче кварталы, икенче һәм өченче кварталы танылa.
4.2. Салым һәм аванс түләүләре салым түләүче-оешмалар тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының 397 статьясындагы 1 пунктында билгеләнгән срокларда түләнергә тиеш.».
2. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставында билгеләнгән тәртиптә халыкка җиткерелергә (бастырып чыгарылырга) тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районының**
**«Вязовка авыл җирлеге "**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **А. Г. Томский**